**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 13 май № 311

г. Казань

«Лаеш техника-икътисад техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен төзү турында

Татарстан Республикасында һөнәри белем бирү системасын реформалаштыру һәм һөнәри белем бирү оешмалары белән идарә итүгә эш бирүчеләрне җәлеп итү чараларын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лаеш техника-икътисад техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесенең һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының гамәлдәге «Лаеш техника-икътисад техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесенең төрен үзгәртү юлы белән, учреждение эшчәнлегенең төп максатларын саклап, «Лаеш техника-икътисад техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен (алга таба – техникум) төзү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Техникумны гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы башкара дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

60 көн эчендә «Лаеш техника-икътисад техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе уставына (алга таба – Устав) тиешле үзгәрешләр кертергә һәм аларны законнар белән билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә;

Уставка кертелә торган үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алган көннән соң 30 көн эчендә техникумның күзәтү советы составын расларга;

30 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына элек «Лаеш техника-икътисад техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесенә беркетелгән, техникум эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле дәүләт мөлкәте исемлеген, шулай ук беркетелә торган күчемсез мөлкәт объектларына техник документларны кертергә;

ел саен Уставы белән күздә тотылган төп эшчәнлеге нигезендә техникум өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен расларга.

4. Техникумның дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата

дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карарында билгеләнгән тәртиптә, тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында әлеге максатларга күздә тотылган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Уставка кертелә торган үзгәрешләрне билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алганнан соң:

30 көн эчендә техникумга оператив идарә итү хокукында Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәтен, шул исәптән элек оператив идарә итү хокукында «Лаеш техника-икътисад техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесенә беркетелгән аеруча кыйммәткә ия күчмә мөлкәтне беркетергә;

120 көн эчендә әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә техникумга беркетелә торган күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирүне тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының җыелма бюджет язмасына тиешле үзгәрешләр кертергә.

7. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, Уставка кертелә торган үзгәрешләрне билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алганнан соң 30 көн эчендә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларын торак урыннар белән тәэмин итүгә нормативлар чыгымнарын раслау турында» 2015 ел, 16 октябрь, 776 нчы карарына аны әлеге карарның 1 нче пунктына туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карар проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\311.docx